ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«20» март 2020 ел — № 192

**Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле исемле бердәм электрон социаль йөртү билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча йөртүдән алынмаган керемнәрне каплау максатларында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан оешмаларга субсидияләр бирү Тәртибе**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш), шәхси эшкуарларга, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында" 2016 елның 6 сентябрендәге 887 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "2010 елда Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетында каралган субсидияләр һәм субвенцияләр бирү турында" 2009 елның 10 мартындагы 134 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле исемле бердәм электрон социаль йөртү билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча йөртүдән алынмаган керемнәрне каплау максатларында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан оешмаларга субсидияләр бирү Тәртибен расларга (кушымта).

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесен Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан 2020 елда Арча муниципаль районының җыелма бюджет бүленешендә каралган акчалар чикләрендә субсидияләр бирү буенча вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://arsk.tatarstan.ru).

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р.Мөхәрәмовка йөкләргә.

Җитәкче И.Ә. Галимуллин

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
20 март 2020 ел;
№ 192 карары
белән расланган

**Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле исемле бердәм электрон социаль йөртү билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча йөртүдән алынмаган керемнәрне каплау максатларында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан оешмаларга субсидияләр бирү Тәртибе**

Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле исемле бердәм электрон социаль йөртү билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча йөртүдән алынмаган керемнәрне каплау максатларында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан оешмаларга субсидияләр (алга таба - субсидияләр) бирү процедурасын билгели.

1. Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләре өчен транспорт хезмәтләреннән бертигез файдалана алу мөмкинлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында бердәм айлык социаль йөртү билеты һәм балалар өчен бердәм айлык социаль йөртү билеты бирү Тәртибен раслау турында" 2005 елның 7 апрелендәге 161 номерлы карары (алга таба - ТР МК 07.04.2005, № 161 карары) нигезендә кертелгән бердәм айлык социаль йөртү билетларын һәм балалар өчен бердәм айлык социаль йөртү билетларын гамәлгә ашыру юлы белән тәэмин ителә.

2. Субсидияләр Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле исемле бердәм электрон социаль

йөртү билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча йөртүдән алынмаган керемнәрне каплауга бирелә.

3. Субсидияләр Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының вәкаләтле органына (алга таба - Вәкаләтле орган) агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетының җыелма бюджет бүленешендә бюджет чыгымнары классификациясенең тиешле кодлары буенча каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга бирелә.

4. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетында тиешле финанс елына каралган субсидияләр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Арча муниципаль районы территориаль бүлегендә ачылган Арча муниципаль районы Башкарма комитетының шәхси счетында исәпкә алына.

5. Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле бердәм электрон социаль йөртү билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча йөртүдән алынмаган керемнәрне каплауга субсидия алуга дәгъва итүчеләр яки субсидия алу өчен гариза һәм документлар бирүгә вәкаләтле башка затлар (алга таба - мөрәҗәгать итүчеләр) Вәкаләтле органга түбәндәге документларны тапшыралар:

1) субсидия бирү турында гариза;

2) җитәкченең вәкаләтләрен раслый торган документ;

3) оешманың Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләү вакыты субсидия алу турында килешү (шартнамә) төзү (яки субсидия бирү турында карар кабул итү) планлаштырылган айдан алдагы айның 1 нче числосына кадәр булган бурычлары булмавы турында субсидия алучының җитәкчесе һәм баш хисапчысы тарафыннан имзаланган һәм

субсидия алучының мөһере сугылган (булган очракта) документ белән расланган белешмәләр;

4) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләре, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән бюджет инвестицияләре һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджеты алдында срогы чыккан башка бурычлар булмавын раслый торган, субсидия алучының җитәкчесе һәм баш хисапчысы тарафыннан имзаланган һәм субсидия алучының мөһере сугылган (булганда) документ белән расланган белешмәләр.

6. Субсидияләр алдагы айның беренче числосына түбәндәге критерийларга туры килгән оешмаларга бирелә:

- оешманың Арча муниципаль районында гомуми файдаланудагы транспортта пассажирлар ташу буенча эшчәнлек алып баруы;

- оешманың Арча муниципаль районында яшәүчеләрне ташу өчен матди-техник чаралары булу;

- оешманың Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча үтәү вакыты Россия Федерациясе законнары нигезендә килеп җиткән бурычы булмау;

- оешманың Арча муниципаль районы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләре, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән бюджет акчаларын кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджеты алдында срогы чыккан башка бурычлары булмау;

- субсидия алучы оешмалар үзгәртеп кору, бетерелү процессында булырга тиеш түгел, аларга карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган булырга тиеш;

- оешманың чит ил юридик заты булып тормавы, шулай ук Россия юридик затының устав (җыелма) капиталында теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган салым билгеләүнең

ташламалы салым режимын бирә торган Исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләре үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләт һәм территорияләрдә (офшор зоналары) урнашкан чит ил юридик затының катнашу өлеше 50 проценттан артмау;

- оешманың башка муниципаль хокукый актлар нигезендә әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга Арча муниципаль районы бюджетыннан акча алмавы.

7. Субсидия күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$К= Птр.оеш. * Т - Втр.оеш.$$

биредә:

К-транспорт оешмасының гражданнарга ташламалы транспорт кушымталы электрон карталар буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле субсидияләр күләме (алга таба-ташламалы транспорт карталары һәм балалар өчен ташламалы транспорт карталары);

Птр.оешмасы – пассажирлар транспортында ташламалы транспорт картасы һәм балалар өчен ташламалы транспорт картасы буенча транспорт оешмасы буенча хисап аена йөрү саны (автоматлаштырылган түләү системасы операторы мәгълүматлары буенча хисап ае өчен транзакцияләрнең факттагы саны);

Т-Арча муниципаль районында һәр транспорт төре буенча закон нигезендә шәһәр эчендә пассажирлар йөртүгә гамәлдәге тариф;

Ташламалы транспорт кушымтасы булган электрон карта белән йөргәндә, озак вакытлы файдалану билеты буенча йөрүгә түләү өчен һәр транспорт төре буенча бер срок эчендә йөрүнең фиксацияләнгән санын алу хокукын бирә торган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты карары белән билгеләнгән тарифлар кулланыла.

Втр.оешмасы – транспорт оешмасының ташламалы транспорт карталарын һәм балалар ташламалы транспорт карталарын тулыландырудан алынган кереме, ул түбәндәге формула буенча билгеләнә:

Втр.оешмасы = В хПтр.оешмасы / П гомуми

биредә:

В-ташламалы транспорт карталарын һәм балалар өчен ташламалы транспорт карталарын тулыландырудан алынган керем, ул тулылыандырылган ташламалы транспорт карталары һәм балалар өчен ташламалы транспорт карталары саныннан һәм ташламалы транспорт картасын тулыландыруның билгеләнгән бәясеннән һәм балалар өчен ташламалы транспорт картасы бәясеннән чыгып билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

В= Цв * Рв + Цд х Рд

биредә:

Цв-ташламалы транспорт картасын тулыландыру бәясе;

Цд-балалар өчен ташламалы транспорт картасын тулыландыру бәясе;

Рв-ташламалы транспорт карталары, берәмлекләр саны;

Рд-гамәлдәге (тулыландырылган) балалар ташламалы транспорт карталары, берәмлекләр саны;

Пгомуми - хисап чоры өчен барлык транспорт оешмалары маршрутларында ташламалы транспорт карталары һәм балалар өчен ташламалы транспорт карталары транзакцияләренең гомуми саны.

Арча муниципаль районының транспорт оешмалары арасында хисап аенда акчаларны бүлү ташламалы категория гражданнарның шәһәр пассажир транспортында йөрүе буенча автоматлаштырылган түләү системасы операторы тарафыннан тапшырыла торган хисаплар ("Транспорт картасы"АҖ) нигезендә ай саен 15 числодан да соңга калмыйча башкарыла.

8. Вәкаләтле орган тапшырылган документларны һәм исәп-хисапларны тикшерә.

9. Субсидияләр Арча муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан оешмаларның кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап

счетларына күчерелә. Субсидияләрне күчерү исәп - хисаплардан соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

10. Түбәндәге очракларда субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителә:

- субсидия алучы тапшырган документларның әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

- субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы;

- оешманың әлеге Тәртиптә күрсәтелгән критерийларга туры килмәве;

- Арча муниципаль районы бюджеты турындагы карарда субсидия түләү өчен каралган акчалар әлеге Тәртип нигезендә субсидия сыйфатында бирелеп беткән булу.

11. Вәкаләтле орган һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле органы оешмаларның субсидияләрдән файдалану шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне мәҗбүри рәвештә тикшерә.

Субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен бозу очраклары ачыкланганда, субсидия алучы тарафыннан субсидияләр Вәкаләтле органның язма таләбе буенча, Арча муниципаль районы бюджетына субсидияне кире кайтару таләпләре алынганнан соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, кире кайтарылырга тиеш. Субсидия билгеләнгән вакытка кире кайтарылмаган очракта, гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә Арча муниципаль районы бюджеты кеременә түләттерелә.